
Бергәләп өйрәник



# Минем өй, минем бистә, минем республика

## Әти-әниләр өчен ярдәмлек

(2-3 яшь)

## Эндәшләр, юаткычлыр

*Үсеп буйга җитәр бу,
Галим булып китәр бу,
Туган-үскән иленә
Тырышып хезмәт итәр бу.
* Тор, тор, тургай,
Таң, таң ата бугай.
Тургай, кил, чыпчык, чык,
Чырык, чырык, чырык!
* Тук, тук, тукран,
Тукылдатып утырам,
Мичтә бәлеш пешәме?
Шуны көтеп утырам.

## *Син — минем нәнием*

Син — минем нәнием,
Табигать җимеше.
Син — минем җирдәге
Йөрәгем тибеше.
Синдә ул кояшның
Яктысы, нурлары.
Син булсаң ямьләнә,
Яшәрә Җир шары.
Яңгырның шифасы,
Җылысы син, балам.
Җиремә гомерлек
Җыр булып кил, балам.
Күлләрдәй серле ул
Күзләрең карасы.
Күзеңә төбәлгән
Туган ил карашы.

*Эльмира Шәрифуллина*

**Әтәчем**

Әтәчем! Әтәчем!
Ник иртә ятасың?
Йокыдан син безне
Иртүк уятасың.
Торасың да иртүк,
Кычкырасың бик күп:
Кикри-күк, кикри-күк,
Кикри-күк, кикри-күк!

*Бари Рәхмәт*

*Хәрәкәтле уен*

**Чебешле тавык**

Тәрбияче – «тавык», ә балалар «чебиләр» булалар. Тавык урындыкта яки келәм өстендә утыра, чебиләр аның янына ук килеп утыралар.Тавык йокымсырап, күзләрен йомып утырган арада,чебиләр әкрен генә төрле якларга йөгереп китәләр, җимэзләнеп йөриләр.Тавык уяна, янында чебиләре юклыкны күрә дә аларны чакыра башлый: «Кыт-кыт-кыт, барыгыз да минем яныма килегез!» – ди. Чебиләр әниләре янына йөгереп киләләр.
Уен кабатлана.

Уенга күрсәтмәләр

- «Чебиләр» бүлмә буйлап йөриләр яки йөгерәләр.
- «Тавык» чакыргач та, «чебиләр» барысы да йөгереп килергә тиешләр.
- Әгәр уен бүлмәдәүткәрелсә, балаларга йөгерүөчен урынны билгеләргә кирәк.